е

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БӘТКЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

## КАРАР

17.12.2019 ел Бәтке авылы № 17

Бәтке авыл җирлеге территориясендә пиротехник эшләнмәләрне куллану урынын билгеләү турында

Яңа ел бәйрәм чараларының, гражданнарның тормышын һәм сәламәтлеген, физик һәм юридик затлар мөлкәтенең, дәүләт яисә муниципаль милекнең янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү максатында, «Янгын куркынычсызлыгы турында» турында 1994 елның 21 декабрендәге 69-ФЗ номерлы Федераль законның 30 статьясы һәм «Янгын куркынычсызлыгы турында» 1993 елның 18 маендагы 1866-XII номерлы Татарстан Республикасы Законының 25 статьясы нигезендә

**КАРАР БИРӘ:**

1. Яңа ел һәм Раштуа чаралары чорында Бәтке авыл җирлеге территориясендә махсуслаштырылган кибетләрдә яисә кибетләрнең махсуслаштырылган бүлекләрендә ирекле сатуда булган I-III классылы хәвефлелектәге (хәвефле зона радиусы 0,5 метрдан 20 метрга кадәр) көнкүреш пиротехника эшләнмәләрен авыл халкы тарафыннан куллану урынын түбәндәге территорияләрдә билгеләргә:

- Бәтке авылында – парк территориясендә;

2. Пиротехника әйберләрен эшләтеп җибәрү өчен мәйданчыкларны кирәкле күләмдә беренчел янгын сүндерү чаралар белән тәэмин итәргә, шулай ук гражданнар көнкүреш пиротехника эшләнмәләрен кулланганда куркынычсызлык чараларын үтәү буенча инструкцияләр урнаштырылган мәгълүмати стендлар белән җиһазландырырга.

3. Әлеге карарны Бәтке авыл җирлегенең махсуслаштырылган мәгълүмат стендларында, районның рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

4. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Бащкарма комитет Җитәкчесе
М.А.Ионычев